МИНИСТЕРСТВО ЗЕМЕЛЬНЫХ И ИМУЩЕСТВЕННЫХ ОТНОШЕНИЙ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ҖИР ҺӘМ МӨЛКӘТ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

от 12.08.2022 Казан ш. № 498-пр

Татарстан Республикасы җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 23.05.2022 № 291-пр боерыгы белән расланган Татарстан Республикасының казна мөлкәте булган торакларны аларны биләп торган Россия Федерациясе гражданнарына милеккә тапшыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында.

1. Татарстан Республикасы җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының “Татарстан Республикасының казна мөлкәте булган торакларны аларны биләп торган Россия Федерациясе гражданнарына милеккә тапшыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында” 23.05.2022 № 291-пр боерыгы белән расланган Татарстан Республикасының казна мөлкәте булган торакларны аларны биләп торган Россия Федерациясе гражданнарына милеккә тапшыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертергә тәкъдим ителгән үзгәрешләрне расларга.

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны министрның беренче урынбасары А.И.Галиевка йөкләргә.

**Министр** **Ф.Ә.Әһлиуллин**

Татарстан Республикасы
Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре
министрлыгының
12.08.2022 № 498-пр
боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының “Татарстан Республикасының казна мөлкәте булган торакларны аларны биләп торган Россия Федерациясе гражданнарына милеккә тапшыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында” 23.05.2022 № 291-пр боерыгы белән расланган Татарстан Республикасының казна мөлкәте булган торакларны аларны биләп торган Россия Федерациясе гражданнарына милеккә тапшыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр

2 бүлектә:

2.4.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.4.2. Дәүләт хезмәте гариза һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) бердәм порталындагы (https:// www.gosuslugi.ru/) (алга таба – Бердәм портал), Республика порталындагы гариза бирүченең шәхси кабинеты (алга таба – шәхси кабинет) аша, Татарстан Республикасы дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталы (https://uslugi.tatarstan.ru/) (алга таба – Республика порталы) аша тапшырылган очракта, эш номенклатурасына туры китереп гаризага Бердәм порталның, Республика порталының шәхси кабинетында күренеп торган номер һәм «Документларны тикшерү» статусы бирелгәннән соң Министрлык тарафыннан 38 көн эчендә күрсәтелә.»;

2.5 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Бердәм порталда, Республика порталында урнаштырыла:»;

2.6.1 пунктның өченче абзацында «Республика порталы» сүзләре алдыннан «Бердәм портал,» сүзләре языла;

2.6.3 пуктның дүртенче абзацын “Республика порталы” сүзләре алдыннан «Бердәм портал,» сүзләре белән тулыландырырга;

2.6.5 пунктның беренче абзацына «документларны» сүзеннән соң «Бердәм портал,» сүзләрен өстәргә;

2.6.7 пунктта «(белешмәләрне)» сүзеннән соң «Бердәм портал,» сүзләрен өстәргә;

2.8.4 пунктның икенче абзацында “нәтиҗәсен алырга” сүзләреннән соң «Бердәм портал,» сүзләрен өстәргә;

2.11.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.11.3. Гариза Бердәм портал, Республика порталы аша юлланса, гариза бирүче гариза бирелгән көнне Бердәм портал, Республика порталындагы шәхси кабинетына һәм электрон почта белән гаризаның җибәрелүен раслаган, гариза бирү датасы күрсәтелгән теркәү номерлы белдерү ала.»;

2.14.4 пунктта:

икенче абзацка “сроклары турында” сүзләреннән соң «Бердәм портал,» сүзләрен өстәргә;

җиденче абзацка “тәэмин итүче” сүзләреннән соң «Бердәм портал,» сүзләрен өстәргә;

сигезенче абзацка “Гариза формалаштыру” сүзләреннән соң «Бердәм портал,» сүзләрен өстәргә;

2.14.5 пунктның алтынчы абзацын “кулланып,” сүзеннән соң «Бердәм портал,» сүзләре белән тулыландырырга;

2.14.7 пунктның икенче абзацында «Министрлык хезмәткәре» сүзләрен «Бүлек белгече» сүзләре белән алмаштырырга;

3 бүлектә:

3.5.1 пунктның дүртенче абзацында «хезмәткәр» сүзен «белгеч» сүзе белән алмаштырырга;

3.5.3 пунктны «шулай ук,» дигән сүздән соң «Бердәм порталда,» дигән сүзләр белән тулыландырырга;

3.5.4 пунктның беренче абзацында «Министрлык хезмәткәре» сүзләрен «Бүлек белгече» сүзләре белән алмаштырырга;

3.6.2.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.6.2.1. Бүлек белгече гариза Бердәм портал, Республика порталы аша бирелгәндә 1 эш көне эчендә, гариза ял яки бәйрәм көнендә керсә – беренче эш көнендә түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

а) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итә, гариза бирүчегә гаризаның килүе турында электрон хәбәр юллый;

б) гаризаны регистрацияли һәм гариза бирүчегә гаризаның регистрацияләнүе турында яки дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында белдерү юллый.

Гариза керүе турында электрон хәбәр һәм гаризаның регистрацияләнүе турында белдерү Республика порталындагы шәхси кабинетта үтенеч язуы каралу статусында автомат рәвештә чагыла.»;

3.6.2.2 пунктта:

беренче абзацны «гариза бирүче» дигән сүздән соң «Бердәм порталда,» дигән сүзләр белән тулыландырырга;

икенче абзацны «Бердәм порталда,» дигән сүзләр белән башларга;

өченче абзацны «Бердәм порталда,» дигән сүзләр белән башларга;

3.6.2.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.6.2.3. Бүлек белгече Республика порталыннан килгән электрон гаризаларның барлыгын тикшерә, көнгә ике тапкырдан да ким булмаган вакытта кергән гаризаларны һәм беркетелгән документларның электрон образларын (документларны) карап чыга.

Эш номенклатурасына туры китереп гаризага номер һәм «Документларны тикшерү» статусы бирә, Республика порталының шәхси кабинетында автомат рәвештә чагыла.

Бүлек белгече карау өчен документлар кергәч:

электрон формада кергән эшләрне, шул исәптән гариза бирүче беркеткән электрон рәвешле документларны һәм документларның электрон образларын карап чыга;

документларның электрон образларының комплектлылыгын, укылышын тикшерә;

Республика порталына мөрәҗәгать итеп электрон имзаның гамәлдә булу шартларының саклануын тикшерә (гариза бирүче тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза куелган документларның электрон образлары бирелгән очракта).

Бүлек белгече әлеге Регламентның 2.7 пунктында күрсәтелгән нигезләр булган очракта дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны кабул итүдән баш тарту турында карар проекты әзерли.

Көчәйтелгән квалификацияле электрон имзаны тикшерү нәтиҗәсендә аның гамәлдә булу шартларының сакланмавы ачыкланса, баш тарту турында карар проекты әлеге карарны кабул итүгә нигез булган № 63 Федераль законның 11 статьясы пунктларын үз эченә алырга тиеш.

Баш тарту сәбәпләре күрсәтелгән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны кабул итүдән баш тарту турында карар проекты (дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны кабул итүдән баш тарту нигезләре әлеге документларга билгеләнгән таләпләрне бозу белән бәйле булган очракта, документларны кабул итүдән баш тарту нигезләре тапшырылмаган документларның атамасы (мәгълүмат, белешмә), дөрес булмаган һәм (яки) каршылыклы мәгълүмат, тиешле тәртипләрнең бозып формалаштырылган) электрон арадашлык системасы аша тиешле тәртиптә килештерүгә юллана.

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны кабул итүдән баш тарту турында карар проектын килештерү Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының Эш башкару инструкциясендә каралган тәртиптә башкарыла.

Бүлек белгече әлеге Регламентның 2.7 пунктында күрсәтелгән нигезләр булмаган очракта “Ведомствоара мәгълүмати арадашлык” административ процедурасын үтәүгә күчә.»;

3.10.1 пунктның икенче абзацын «һәм (яки)» дигән сүзләрдән соң «Бердәм порталда,» дигән сүзләр белән тулыландырырга;

3.10.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.10.2. Административ процедуралар башкаруны башлау өчен нигез булып контроль бүлеге белгеченең дәүләт хезмәте күрсәтүне раслаучы документны (торакны бирү турында карар проекты һәм торакны бирү шартнамәсе) яки баш тарту турында карарны алуы тора.

Контроль бүлеге белгече дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсенә регистрация үткәрә.

Бүлек белгече:

дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе турындагы мәгълүматны дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмати системасының документацияләр алып бару подсистемасына кертә;

гариза бирүчегә (аның вәкиленә) Бердәм портал, Республика порталы аша электрон арадашлык юлы белән дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе турында һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен МФЦдан, Министрлыктан алу мөмкинлеге турында хәбәр итә.

Процедуралар техник мөмкинлек булганда дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмати системасыны кулланып автомат режимда башкарыла.

Әлеге пункт билгели торган процедуралар дәүләт хезмәте күрсәтүне (күрсәтүдән баш тартуны) раслаган документка имза куелган көндә башкарыла.

Административ процедуралар башкарылу нәтиҗәсе: дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе турында мәгълүматны мәгълүмат системаларына урнаштыру, гариза бирүчегә (аның вәкиленә) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе һәм аны алу ысуллары турында хәбәр итү.»;

3.10.4 пунктта:

беренче абзацны «нәтиҗәсен алырга» дигән сүзләрдән соң «Бердәм порталда,» дигән сүзләр белән тулыландырырга;

өченче абзацны «баш тартуны,» дигән сүзләрдән соң «Бердәм порталда,» дигән сүзләр белән тулыландырырга;

Регламентка 1 нче кушымтада «кәгазьдә;» дигән сүздән соң «Бердәм порталда,» дигән сүзләр белән тулыландырырга.